**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

# Татарстан Республикасында хезмәт өлкәсендә социаль партнерлыкны үстерү турында

Хезмәт өлкәсендә социаль партнерлык системасын алга таба да үстерү һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары, җирле үзидарә органнары, эш бирүчеләр һәм аларның берләшмәләре, Татарстан Республикасында һөнәр берлекләренең (һөнәр берлекләре берләшмәләренең) үзара хезмәттәшлеге нәтиҗәлелеген арттыру максатларында **карар бирәм**:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына, министрлыкларга, Татарстан Республикасы дәүләт комитетлары һәм ведомстволарына:

Татарстан Республикасы территориясендә һөнәр берлекләре (һөнәр берлекләре берләшмәләре) эшчәнлеге өчен кирәкле шартлар тудыруга булышлык күрсәтергә;

социаль-хезмәт мөнәсәбәтләрен җайга салу комиссияләренең (тиешле һөнәр берлекләренең (һөнәр берлекләре берләшмәләренең) һәм эш бирүчеләр берләшмәләренең) хезмәт өлкәсенә кагылышлы закон һәм башка норматив хокукый актларны, социаль-икътисадый үсеш программаларын, дәүләт хакимияте органнарының башка актлары проектларын эшләүдә һәм (яисә) фикер алышуда катнашуы өчен шартлар тәэмин итәргә;

һөнәр берлекләре (һөнәр берлекләре берләшмәләре) эшчәнлегенә тыкшынуларны булдырмаска.

2. Татарстан Республикасы Һөнәр берлекләре федерациясенә, Татарстан Республикасы эш бирүчеләр берлекләренең координация советына, Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары җирле үзидарә органнарына түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә:

муниципаль районнар һәм шәһәр округлары җирле үзидарә органнары, һөнәр берлекләре берләшмәләре һәм эш бирүчеләр арасында социаль-хезмәт мөнәсәбәтләрен җайга салу турында өчъяклы тармак һәм территориаль килешүләр төзү практикасын үстерергә;

хезмәт өлкәсендә социаль партнерлыкның территориаль дәрәҗәсендә эш бирүчеләрнең берләшмәләрен, башлангыч һөнәр берлекләре

оешмаларын, социаль-хезмәт мөнәсәбәтләрен җайга салу буенча өчъяклы территориаль комиссияләр төзүгә ярдәм күрсәтергә;

хезмәт өлкәсендә социаль партнерлыкны барлык оештыру-хокукый һәм милекчелек рәвешләрендәге оешмаларда социаль-хезмәт мөнәсәбәтләрен шартнамә нигезендә коллектив җайга салу практикасын үстерү буенча чараларны гамәлгә ашыру, социаль-хезмәт мөнәсәбәтләре һәм алар белән бәйле икътисадый мөнәсәбәтләр өлкәсен мониторинглау нәтиҗәләре буенча чаралар уздыру системасын камилләштерергә.

3. Хезмәт өлкәсендә социаль партнерлыкның барлык дәрәҗәләрендә катнашучы якларга түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә:

хезмәт өлкәсендә социаль партнерлыкның барлык дәрәҗәләрендә төзелә торган барлык килешүләрне, оешмаларның конкурентлыкка сәләтлелеген саклап калуга, хезмәткәрләрне эш белән тәэмин итүгә һәм аларның социаль яклануына булышлык күрсәтүгә юнәлтелгән коллектив шартнамәләр һәм кризиска каршы программаларны гамәлгә ашыру мәсьәләләре буенча мәгълүмати-аңлату эше алып барырга;

хезмәт өлкәсендә социаль партнерлыкның барлык дәрәҗәләрендә төзелә торган килешүләргә һәм коллектив шартнамәләргә төбәк һәм тармак килешүләренең төп нигезләмәләрен кертүне тәэмин итәргә.

4. Әлеге Указның үтәлешен контрольдә тотуны Социаль-хезмәт мөнәсәбәтләрен җайга салу буенча республика өчъяклы комиссиясе координаторына йөкләргә.

5. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы**
**Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**

Казан,Кремль
2015 ел, 17 ноябрь
№ ПУ-1105